| СОВЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ |
|---|---|

РЕШЕНИЕ КАРАР

09.09.2025 ел Баулы шәһәре № 324

Баулы муниципаль районы Советының 2012 елның 18 маендагы 105 номерлы карары белән расланган, «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасы» муниципаль казна учреждениесе турында Нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясе Җир кодексының 11.10 һәм 39.15 статьяларына һәм «Геодезия, картография һәм пространство мәгълүматлары турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның 18.1 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 08 августындагы 317-ФЗ номерлы Федераль законы, «Пространство мәгълүматларының милли системасы» бердәм цифрлы платформасы» федераль дәүләт географик мәгълүмат системасы турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 07 июнендәге 1040 номерлы карары нигезендә, Баулы муниципаль район Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Баулы муниципаль районы Советының 2012 елның 18 маендагы 105 номерлы карары белән расланган, «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасы» муниципаль казна учреждениесе турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

3 бүлектә:

3.12., 3.13., 3.14., 3.15., 3.36., пунктларын үз көчен югалткан дип танырга;

3.18. пунктында «муниципаль унитар предприятиеләр» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.19. пунктында беренче җөмләне төшереп калдырырга, икенче абзацта «муниципаль унитар предприятиеләр,» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.20. пунктында «муниципаль унитар предприятиеләр һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.22. пунктында «муниципаль унитар предприятиеләр һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.25. пунктында «шул исәптән хосусыйлаштыру процессында төзелә торган муниципаль унитар предприятиеләрне» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.34. пунктының беренче абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

3.41. пункты белән түбәндәге эчтәлектә тулыландырырга:

«3.41. Үз вәкаләтләрен тәэмин итү өчен Палата дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системаларын, шулай ук пространство белешмәләренең милли системасы эшләвен тәэмин итә торган федераль дәүләт географик мәгълүмат системасын файдаланырга хокуклы.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль район Советының җирле үзидарә, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Баулы муниципаль районы Башлыгы,
район Советы Рәисе И.И. Гозәеров